Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге

# КАРАР

2023 елның 30 сентябрь, № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында гражданнар Җыенының 2022 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы мәсьәлә буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Кукмара авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Янсыбы авылында халык җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Янсыбы авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:
9 нче пункт белән тулыландырырга:
«9. Яңа сууткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә: Җыенда сайлау хокукына ия булучылар 246 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 127 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 127 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Янсыбы авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре-гамәлдә, дип танырга.

2. «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегендәге Янсыбы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында " 2022 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Янсыбы авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:
9 нче пункт белән тулыландырырга:
«9. Яңа суүткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү »

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән

3. Җыенның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев